Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 13
(26)

26 апрель
2012 ел

## • Ректорат яңалыклары

23 апрель көнне КФУ ректоры Илшат Гафуров җитәкчелегендә ректоратның чираттагы утырышы узды.

Көн тәртибенә куелган сорауларны тикшерә башлаганчы, Илшат Гафуров уку йорты тарихы музеена бәйле чыккан имеш-мимешләргә тукталды. «Музейны башка бинага күчерәләр яисә бөтенләй ябалар дигән сүзләр университет җитәкчелегенә, коллективка ышанмавыгызны күрсәтә», – диде һәм узган утырышның берсендә музейларга бәйле проблеманың инде күтәрелгәнлеген искә төшерде. Аның фикеренчә, Тарих институтының үз музее булырга тиеш. Шулай ук Университет тарихы музеен тагын да тулыландырырга, КФУ составына кушылган 3 университет тарихы да биредә урын алырга тиешлеген ассызыклады. Музей өчен махсус бина да булырга тиеш, аның эшчәнлеге белән шәһәр кешеләренә дә танышырга мөмкин булсын. Әлеге сораулар белән киләчәктә университет президенты М.Сәләхов җитәкчелегендәге комиссия шөгыльләнәчәк.

Алга таба икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин КФУ ның Үсеш программасына бәйле яңа мәгълүматлар җиткерде. Конкурс аша үткән 3-4 курста укучы талантлы студентлар, бакалавр-магистрлар, аспирантлар өчен игълан ителгән махсус British Petroleum (BP) Exploration Operating Company Limited стипендиаль программасы турында сөйләде. Күптән түгел генә BP компаниясе белән төзелгән килешү нигезендә укыту һәм тикшеренү эшләренә җәлеп ителгән профессорларга ярдәм күрсәтеләчәк. Компания талантлы яшьләрне барлау өчен, 14 өстенлекле юнәлешне билгеләде. Гаризалар компаниянең порталы аша апрель азагына кадәр кабул ителә.

КФУда инженериягә бәйле белем бирүнең торышы һәм үсеше турында инновацион эшчәнлек буенча проректор Н.Кашапов сөйләде. Әлеге юнәлештә белем бирү буенча барлыгы 11 программа бар, киләчәктә яңа программалар да тормышка ашырылачак.

Укыту-методик идарә җитәкчесе О.Тимофеева докладына академик консультантларга (тьюторлар) бәйле нигезләмәгә багышланды. Һәр институт яисә факультетта тьюторлар булырга тиеш, ләкин алар кемгә буйсыначак? Куратордан нәрсәсе белән аерыла? Әлеге чыгыш утырышта катнашучылар арасында зур кызыксыну уятты. Ректор бу мәсьәләне ныклап өйрәнергә кушты.

Финанс һәм икътисад институтының Үсеш программасы турындагы презентацияне директор Ш.Вәлитов тәкъдим итте. Чыгышын институт эшчәнлеген яктырткан видеоролик белән башлап җибәрде. Кадрлар составы, структура, институтның партнёрлары турында мәгълүмат бирде. Ректор чыгыш буенча үз тәкъдимнәрен җиткерде, Финанс һәи икътисад институты Идарә итү һәм территориаль үсеш институты белән тыгыз элемтәдә торырга тиешлеген ассызыклады. Шулай ук бизнес-инкубатор төзү соравы да каралды.

Утырышта ректорның өстәмә хезмәт хакына тәкъдим ителүче 15 хезмәткәрнең исеме дә аталды. Бүгенге көндә өстәмә түләүне 5 кеше ала.

Төрлеләр бүлегендә уку-укыту эшләре буенча проректор Рияз Минзарипов бу уку елына кабул итүнең төп саннары белән таныштырды. 2012-2013 елда 5988 кеше кабул ителәчәк, узган ел белән чагыштырганда, бу 1801 гә күбрәк дигән сүз.

Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры Р.Латыйпов «Гамәли математика һәм информатика» юнәлеше буенча ачылачак «Мәгълүматларны анализлау һәм аларның кушымталары» дигән яңа магистрлык программасы турында сөйләде.

Шулай ук ректорат кысаларында София университеты белән хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куелды (тулырак 2 нче биттә).

*Динара ӘХМӘТОВА,*
*хәбәрче*



Руслан Гыйниятов фотосы

# «Барсына да Гран-при бирер идек»...

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Кичә, ягъни 25 апрель көнне, «УНИКС» концертлар залында «Студентлар язы – 2012» фестиваленең Гала-концерты узды.

Ничә айлар дәвамында барган репетицияләр, сайлап алу турлары, йокламыйча калган төннәр, укымыйча узган паралар, ару-талулар – барысы да артта калды. Бу көнне шатлыклы да, бераз моңсу да кебек тоелды...

20 институт һәм факультетның һәр чыгышын игътибар белән карап, бәя биреп утырган мәртәбәле жюри әгъзаларына җиңүчеләрне билгеләү җиңел булмый. «Кулыбыздан килсә, барсына да Гран-при бирер идек», – ди алар. Жюри рәисе, сәнгать бүлеге мөдире, сәнгать һәм дөнья мәдәнияте теориясе кафедрасы җитәкчесе, педагогика фәннәре докторы, профессор Зилия Явгильдина номерларның эчтәлекле, югары сыйфатлы булуын ассызыклый: «Идарә итү һәм территориаль үсеш институтының концерт программасын аерып әйтәсе килә. Алар яшьләр өчен актуаль проблемаларны күтәрде. Филология һәм сәнгать институты профессиональлеге белән алга чыкты. Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты талантлары һәрвакыттагыча бәйрәмчә кәеф, якты номерлар бүләк итте. Журналистика һәм социология факультеты осталары сәхнәдә дә һөнәрләренә тугры кала белә. Алар гел эзләнүдә, креатив, иҗади. Физика институты исә «физиклар - лириклар» рухи бердәмлеген дәлилләде, программалары шигъри юлларга бай иде».

Шулай ук жюри рәисе филиалларда узган сайлап алу турларын да бик югары бәяләде. Аның сүзләренчә, биредә студентлар бөтен җанын-тәнен биреп эшли. Алар өчен нәтиҗә мөһим булмаска да мөмкин, беренче чиратта, күңелле яшәү рәвеше тора.

Иң куандырганы: әле студент тормышын аңлап та бетермәгән студентлар фестивальдә үз талантларын күрсәтергә куркып тормый. Дөрес, 3-4 курс студентлары күпчелекне алып тора. Алар инде һәр кимчелекне, һәр нюансны белә, җитәкчеләрне бер сүздән аңлый. Фестиваль шулай итеп яңа лидерларны, яшь йолдызларны зур тормышка әзерли.

«Ирешелгән уңышта туктап калырга ярамый. Киләсе елга номинацияләр, оригиналь жанрлар, катнашучылар саны күбрәк булыр дип ышанабыз. Алга таба аларны да искә алачакбыз. «УНИКС» концертлар залында мөмкинлекләр күп, һәркайсыннан файдаланырга кирәк. Әлбәттә, институт һәм факультет җитәкчеләренә зур рәхмәт сүзләре җиткерәбез», – диде Зилия Мөхтәр кызы.

## • «Милли хәзинә - 2012»

# Халык җәүһәрләрен барлап

**Гөлшаһидә ДАУТОВА,**
ifi.kpfu.ru сайты хәбәрчесе

24 апрель көнне «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгында Идел буе яшьләренең халыкара иҗади «Милли хәзинә» конкурс-фестиваленә багышланган матбугат конференциясе узды.



Журналистларның сорауларына Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, сәнгать бүлеге җитәкчесе, жюри рәисе Зилия Явгильдина, «Мизгел» халык театры режиссёры Марсель Җаббаров җавап бирде.

Р.Җамалетдинов әйтеп үткәнчә, бу елда III фестиваль-конкурста югары һәм урта махсус уку йортлары гына түгел, өстәмә белем бирү учреждениеләре һәм мәктәп укучылары да катнаша. «Фестиваль төрле милләттән булган яшьләр арасында толерантлык тәрбияләү, туган илгә, мәдәнияткә, халык гореф-гадәтләренә мәхәббәт уятуга юнәлдерелгән», – диде ул үз чыгышында.

**Ахыры 3нче биттә.**

## Ике авыз сүз

25 апрель көнне «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында VII Казан венчур ярминкәсе узды. 2005 елдан бирле үткәрелә торган ярминкәгә Россиядән генә түгел, чит илләрдән дә эшмәкәрләр килә. Быел Россиянең күп шәһәрләреннән, Литва, Кытайдан килгән компания вәкилләре бар иде. Чарада КФУ ректоры Илшат Гафуров та катнашты. Безнең кече инновацион предприятиеләр тәкъдим ителде.

• • • •

Шулай ук 25 апрель көнне КФУга Educare Co-operative Limited (Сингапур) делегациясе килде. Алар Казан федераль университеты эшчәнлеге, аның үсеш юнәлешләре белән таныштылар. Кунаклар өчен Университет тарихы музеена экскурсия оештырылды.

• • • •

Кичә КФУда Саклык банкы корпоратив университетының төбәк мәйданчыгы ачылды. Корпоратив университет кадрлар әзерләүдә яңа укыту стандартлары булдыруны, корпоратив программалар һәм «Саклык банкы»ның үсеш стратегиясе тәҗрибәсен тормышка ашыруны максат итеп куя. Укыту төрле форматта алып барылачак. Традицион белем бирүдән тыш, уңышлы юнәлешләр буенча дистанцион һәм проектлы укыту да булачак.

• • • •

24 апрель көнне Филология һәм сәнгать институтында академик, Россия тюркологлары арасында абруйлы галим Әдһәм Тенишевка багышланган Халыкара тюркологик симпозиум булып узды. Чарада Стамбул, Ташкент, Казан, Алабуга, Яр Чаллы галимнәре фикер алышты.

• • • •

25-28 апрель көннәрендә КФУда «Психологик фәннең һәм практиканың заманча тенденцияләре» дип аталган халыкара фәнни форум уза. Төп максаты – психология фәне үсешенә бәйле фәнни проблемаларны чишү урыны булдыру. Педагогика һәм психология институтының психология бүлегендә мастер-класслар һәм тренинглар, доктор-класслар һәм секцион утырышлар, «түгәрәк өстәл»ләр үтә, әлеге бүлек студентлары һәм аспирантлар доклад белән чыгыш ясый. Форум кысаларында Казан Кремле музейларына бушлай керү һәм башка бик күп сюрпризлар каралган.

• • • •

Бүген Кайгыртучанлык советының утырышлар залында 15 сәгатьтә КФУ ның Гыйльми советы утырышы уза.

• • • •

Шулай ук бүген юридик факультетта Павия университетының (Италия) хокук фәннәре докторы, профессор Э.Сильвестри катнашында «Европа һәм Россиядә медиация: теория һәм практиканың проблемалары» дигән «түгәрәк өстәл» узды. Заманча медиация, гаилә, җинаять эшләре медиациясе кебек сорауларны яктыртылды. Россия һәм Европа илләренең медиациясендәге аермалыклар күрсәтелде.

• • • •

Бүген КФУда «Россия-Германиянең белем бирүдә хезмәттәшлеге: югары белем бирү өлкәсендә Европа программаларының керткән өлеше» дигән халыкара конференция ачылды. Конференция эшчәнлеге 27 апрельгә кадәр дәвам итә.

• • • •

24 апрель көнне журналистика һәм социология факультетында «Телевидение һәм кинода карьера: эчке яктан караш» исемле «түгәрәк өстәл» узды. Телевидениенең бүгенге хәленә, кинога бәйле проблемалар каралды. 27 апрель көнне «TV-ое время – 2012» III телевизион студентлар фестивале кысаларында брейн-ринг булачак.

• • • •

Күптән түгел химия буенча Магнитогорскиның Г.И.Носов исемендәге дәүләт техник университеты базасында 9-11 сыйныф укучылары арасында 48 нче Бөтенроссия укучылар олимпиадасының 2012 елгы йомгаклау этабы узды. Россия Федерациясенең 62 төбәгеннән зур сынаулар узып килгән 202 укучы көч сынашты. Жюри составында Казан федераль университетының өлкән фәнни хезмәткәре, химия фәннәре кандидаты Игорь Седов та бар иде. Ике теоретик һәм бер эксперименталь турларны узганнан соң, Россия күләмендә җиңүчеләрнең исемнәре игълан ителде. Татарстаннан килгән 13 укучының 5 се җиңү яулады.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*

• Халыкара бәйләнешләр

# Уртак эшләргә нигез

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

23 апрель көнне Казан университетына Изге Климент Охридский исемендәге София университетыннан делегация килде. Аның составында ректор, профессор И.Ильчев, Болгария Президенты киңәшчесе П.Кынев бар иде.

София университетына Болгарияне азат итеп, 10 ел үткәннән соң, 1888 елда нигез салына. Ул славян язуына нигез салучыларның берсе Изге Климент Охридский исемен йөртә. 16 (23) факультеты булган уку йортында 14 (25) меңгә якын студент белем ала.

Визит барышында кунаклар университет тарихы музее, сирәк кульязмалар һәм китаплар бүлегендә, Педагогика һәм психология институтында булдылар. КФУ ректоры И.Гафуров һәм институт директорлары белән очраштылар.

Очрашу вакытында традицион рәвештә хезмәттәшлек итү мәсьәләләре каралды. Әлеге ике университет инде күп еллар бергә эшли, 2007 елда хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куела. Шуның нигезендә ике уку йортының да профессорлары һәм хезмәткәрләре София һәм Казанда уза торган фәнни конференцияләрдә актив катнаша.



Алия Галимуллина фотосы

Алга таба хезмәттәшлек тагын да ныгыячак, яңа юнәлешләр ачылачак. Кунаклар һәрьяклап уртак эшчәнлек алып барырга әзер булуларын белдерде. И.Гафуров табигый фәннәр өлкәсендә хезмәттәшлек итү мәсьәләсен карарга тәкъдим итте. Кунаклар Физика институты, Геология һәм кара алтынгаз технологияләре институты эшчәнлеге белән таныштылар. Делегация вәкилләрендә Филология һәм сәнгать институты, Тарих институты белән хезмәттәшлек итү дә кызыксыну уятты.

Очрашуга нәтиҗә ясап, Казан федераль университеты һәм Изге Климент Охридский исемендәге София университеты арасындагы хезмәттәшлекне озайту турындагы килешүгә кул куелды. Аның кысаларында педагогик белем бирү өлкәсе буенча уртак магистрлык программасы ачу, укытучыларны стажировка үткәртү, студентлар белән алмашу, уртак фәнни конференция һәм семинарлар уздыру, югары педагогик белем бирү өлкәсендә Россия-Болгария университетара фәнни лаборатория төзү планлаштырыла.

• Бездә кунак бар

# Казан - Ерак Көнчыгыш арасы

**Матбугат үзәге**

Кичә Казан федераль университетына Приморье крае Губернаторы Владимир Миклушевский килде.

Кунакны КФУ ректоры Илшат Гафуров каршы алды. Владимир Миклушевский (фоторәсемдә - уртада) Физика институтында булды, нечкә плёнкалы системалар синтезы, фемтосекундлы спектроскопия, микроскопия һ.б. укыту һәм фәнни лабораторияләрне карады. Институт директоры Альберт Аганов һәм хезмәткәрләр КФУда алып барыла торган тикшеренүләр турында сөйләде.



Диана Поварова фотосы

«Казанда минем булганым бар, ләкин Казан федераль университетында – беренче тапкыр. Бик ошады. Мин чын заманча лабораторияләрдә булдым. Хәзер иң мөһиме: студентларның да, укытучыларның да университет өчен әһәмиятле булган фундаменталь якка гына түгел, ә кешеләр өчен файда китерердәй гамәли тикшеренүләргә дә өстенлек бирүе шарт. КФУ һәм Ерак Көнчыгыш федераль университеты арасында хезмәттәшлек җепләре билгеләнгән. Без инде күптән биомедицина, дару препаратлары, су асты аппаратлары, җир асты байлыкларын тикшерү, диңгезнең биотөрлелеге һәм диңгез биологиясе белән бәйле мәсьәләләр турында фикер алышабыз», – дип билгеләп үтте Владимир Миклушевский визит ахырында.

• Өйрәтәләр мәктәпләрдә

# Профессор Хиггинста кунакта...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Филология һәм сәнгать институтында кызыклы бер чара булып үтте. Республикакүләм конкурс Татарстанның барлык районнарыннан яшь инглиз теле белгечләрен җыйды һәм ул быел икенче тапкыр үткәрелде. Төп оештыручылар роман-герман филологиясе бүлегенең Диана Сабирова җитәкчелегендәге чит телләр кафедрасы иде.

Чараның максаты мәктәптә инглиз теле дәресләрендә фонетикага аеруча нык басым ясауны күздә тота иде. Очрашуга Татарстан мәктәпләренең 5-11 сыйныф укучылары зур кызыксыну белән килгәннәр. Филология һәм сәнгать институты директоры исеменнән кунакларны фәнни эшләр буенча директор урынбасары Искәндәр Ярмәкәев котлады. «Инглиз теле ул – дөньядагы иң популяр тел. Бүгенге көндә аны белмәү хәтта сәер тоела. Ә чит телнең фонетикасын камил белү – телне ни дәрәҗәдә яхшы өйрәнүнең күрсәткече. Уйлап карагыз: сез телне беләсез, сөйләшәсез дә, ләкин башкалар аңламый. Бу очракта чит тел беләм дип йөрүнең бер генә тамчы да файдасы булмаячак...» – дип, үз чыгышында конкурсантларга уңышлар теләде ул.

Чара юкка гына нәкъ менә апрель аенда үткәрелми. Ул инглиз теле көненә багышланган иде. Бу дата 23 апрельдә, бөек драматург һәм шагыйрь Уильям Шекспирның туган көнендә билгеләп үтелә.

Роман-герман филологиясе бүлегенең җитәкчесе, профессор Аида Садыйкова катнашучыларны тел бәйрәме белән тәбрикләде һәм, әлбәттә, бу укучыларны киләчәктә үзебезнең университет студентлары итеп күрергә теләвен белдерде. Рәсми өлештән соң укучылар секцияләргә бүленделәр. Өйгә бирелгән эшләр, кызыклы разминкалар һ.б. фонетик күнекмәләрбеләнтаныштырулары аеруча да күңелле иде. Сокланырлык: хәзерге укучылар инде кечкенә яшьтән үк чит телнең кирәклеген аңлап үсәләр, иң мөһиме, аны теләп өйрәнәләр. Аудитория ишеге төбендә җыелып торган балаларны күргәч, яннарыннан тыныч кына узып китә алмадым. Чит телне яратасызмы соң, дигән сорау аларга берникадәр сәер дә тоелды булса кирәк. «Әлбәттә, шулай булмаса, монда алып килмәсләр дә иде безне», – ди алар. Ә киләчәктә һөнәр сайлаганда, бу тел сезгә кирәк булырмы соң, дигәч: «Мин берәр зур фирмада эшлиячәкмен, без анда чит ил кешеләре белән аралашачакбыз, шуңа күрә мин, үсеп җиткәч, инглиз телен туган телем кебек камил белергә телим», – диде Апас ягыннан килгән V сыйныф укучысы.

Мондый төрдәге чараларның әһәмиятле булуы укучыларның әзерлекләреннән үк күренеп тора иде. Аларның максатчанлыгы һәм тел өйрәнүгә җитди карашлары – куанычлы хәл. Чит телне тиешле дәрәҗәдә өйрәтә белерлек укытучылар гына булсын!

● Бүген Шигърият бәйрәме

# «Берсе тауның биеклегендә, икенчесе итәгендә кала...»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай бөтен табигать яшәреп, җанланган чор – апрель аенда дөньяга килгән. Апрель ае ук аны бездән алып киткән... Бөек шагыйребезнең истәлегенә 26 апрельдә ел саен Шигърият бәйрәме уздырыла.

Татарстан Республикасында гына түгел, Мәскәү шәһәрендә дә Габдулла Тукайның тууына 126 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәме уза. Әлеге бәйрәм үткән ел Мәскәүнең Новокузнецк урамында куелган Тукай һәйкәле янында оештырыла. Кайда гына булмасын, бәйрәм ниндидер рухлану, җанлану белән тулы. Шулай да Шигърият бәйрәменең аеруча дулкынландыргыч мизгелләре – Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатларын игълан итүдер, мөгаен. Бу уңайдан университетыбызның әдәбият галимнәре, укытучылары ниндирәк фикердә икән соң? Гомумән, үлмәс шагыйребез Габдулла Тукай исемендәге бүләк үзенең лаеклы кешеләрен табамы?



**Тәлгат Галиуллин, татар филологиясе бүлеге профессоры:** «Әлбәттә, Тукай премиясе, һичшиксез, булырга, тагын да югары, абруйлы булырга тиеш. Беренчедән, ул безнең бөек шагыйребез исеме белән бәйләнгән. Һәм үзеннән-үзе шундый сорау килеп туа: Тукай премиясе бары тик әдәбият белгечләре, язучыларга гына бирелсә, отышлырак булмасмы икән? Чөнки сәнгать буенча безнең бөек Бакый Урманче, композиторлар арасыннан Салих Сәйдәшев бар бит. Миңа калса, аларның бүләкләре дә булдырылырга тиеш. Дәүләт премиясен бирә торган комиссиядә күбрәк түрәләр утыра. Әйтик, театр директорлары, композиторлар, язучылар берлегенең хуҗалары. Әдәбиятны өйрәнгән кешеләр анда юк диярлек. Күбесе әдәби әсәрләрнең эчтәлеген дә тиешле рәвештә белеп бетермиләр. Ниһаять, тагын бер нәрсә: конкурсантларның үзләре арасында да әдәбиятны яхшы белүчеләр сирәк. Беренче премия Әхмәт Фәйзигә бирелде, ул, дөрестән дә, әдәбият белгече, бөек язучы иде. Ә күпмедер вакыттан соң, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе үзенең кыйммәтен югалта башлады. Мәсәлән, бер җыр җырлаган өчен, бер рәсем ясаган, бер спектакль уйнаган өчен бүләкләп, бу дәрәҗәле премиянең бәһасен шактый төшерделәр. Киләчәктә безнең җәмгыять алдында торган төп мәсьәлә – Тукай бүләгенең бәясен күтәрү. Моның өчен комиссиядә дә әдәбиятны, татар халкының тарихын, телен белгән кешеләр утырырга тиеш дип саныйм. Шуннан башка аның абруен күтәреп булмаячак».



**Флёра Ганиева, татар филологиясе бүлеге профессоры:** «Кандидатларны тәкъдим итүнең уңай ягы бар, шул ук вакытта тискәре ягы да бар. Чөнки кандидатлар Тукай премиясенең таләпләренә, эчтәлегенә, дәрәҗәсенә бөтенесе бертигез лаек түгел. Тәкъдим ителгән кандидатлар арасында аерма бик зур. Мин әдәбиятчы буларак, шагыйрьләр арасыннан Розалина Шаһиеваны искиткеч әдәбиятчы дип саныйм. Ул әдәбиятны әдәбиятчы буларак кына түгел, сәнгатьнең бер төре буларак күрсәтә. Шигырьләрендә Көнчыгыштан килгән традицияләр шулкадәр әйбәт саклаган, халкының югалмаска тиешле матур кыйммәтләрен дә җиткерә belә. Хәзерге көндә әдәбиятта, безне рухландыра торган омтылыш, эстетик идеал юк. Һәркем үз күңелендә шушы идеалларны саклый, әмма аны бергәләп бөтен әдәбият күмәк сакларга тиеш дип уйлыйм. Эстетик идеал ул безнең гомуми хәзинәбез булырга тиеш. Хәзерге әдәбият менә шуны югалтып бара. Розалина Шаһиевада шул идеалларның әле дә булса саклануы мине сокландыра. Тукай традицияләре дә чагылыш таба. Башка конкурсантларның үз урыннары шулай ук бар, һичшиксез, алар да әдәбиятта яшәргә хаклы. Ләкин чагыштыра башладыкмы, берсе тауның биеклегендә, икенчесе аның итәгендә кала. Тагын шунысы да бар: шигырь язган һәрбер кеше шагыйрь була алмый. Бу мәгълүм хакыйкать. Ә инде Тукай премиясенә, гомумән дә, шигырь язган һәрбер кешене тәкъдим итеп булмый. Тукай шигырьләренең әһәмияте торган саен ачыла барган көндә, бу дәрәҗәле исемгә лаеклы дип саналучы кешеләргә карата аеруча да таләпчән булырга кирәк. Сайлаучылар арасында әдәбиятка һәм хәтта сәнгатькә турыдан-туры мөнәсәбәте булмаган кешеләрнең утыруы да күңелне тырнап тора...»



**Хатыйп Миңнегулов, татар филологиясе бүлеге профессоры:** «Әлбәттә, идеаль планда Тукай бүләгенә җавап бирерлек кешеләр ул сирәк. Бездә бит чагыштырмача лаеклы дигән төшенчә дә бар. Шуңа күрә бөтен булган материалына карап, бар булган әсәрләргә, аның төрле тармаклап иҗатына карап, шуларны исәпкә алып бирелергә тиеш ул. Тагын шундый ситуация дә килеп чыгарга мөмкин: алдан ук чикләрне төгәл билгеләп, катгый таләпләр куйсак, премиягә лаек кешеләр быел бөтенләй булмаска мөмкин, аннан соңгы елларда да, бәлки, күренмәсләр. Аннары инде без бөтенләй ул премиянең барлыгын онытырга мөмкинбез. Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә ияләрне сайлаган вакытта, чагыштырмача лаек булырлык хезмәтләрне, әсәрләрне карарга кирәк дип саныйм. Аннан соң Тукай премиясе дөрес түгел, дип әйтергә безнең хакыбыз юк. Аның комиссиясе, тикшерүчеләре бар, ул инде бөтенләй лаек түгел хезмәтләргә бирелми. Бу әсәрләрне мин ничә ел күзәтеп барам, уйлап карасак, аларның һәммәсе дә билгеле бер дәрәҗәдә безнең сәнгатебезгә, әдәбиятыбызга өлеш керткәннәр. Шуның белән бергә кайвакыт әйбәт әсәрләрнең булуын күрәсең, аңлыйсың, ләкин авторлары бик тыйнак кешеләр, үз-үзләрен күрсәтмиләр, әсәрләрен танытмыйлар һәм алар каядыр кырыйда кала. Киресенчә, сүзләре бик үтемле, активлыклары көчле буган авторлар да бар. Аннары премияне биргәнче үк мәгълүмат чараларындагы җәмәгатьчелек фикерен дә исәпкә алырга кирәктер, миңа калса. Болай эшләгәндә әсәрләрне сайлау процессы күпкә җиңелрәк булыр иде».



**Фәрит Яхин, татар филологиясе бүлеге профессоры:** «Минем уйлавымча, барысы да лаеклы, барысы да милләт өчен, шигърият, әдәбият өчен, мәдәниятебезнең үсеше өчен эшлиләр. Һәм комиссия дә юкка куелмаган бит инде. Ә гаделлек, гаделсезлек мәсьәләсе аларның намусында кала. Алар Тукай бүләгенә чын мәгънәсендә лаеклы кешеләрне сайлап ала белергә тиеш. Былгы кандидатлар арасында, иң беренче итеп, бу дәрәҗәле бүләкне Камил Кәримовка бирер идем».



**Әлфинур Нәҗипова, татар филологиясе бүлеге доценты:** «Телевидение, матбугат чараларыннан һәрвакыт бу өлкәгә караган язмаларны укып, кызыксынып барам. Менә бу кеше лаек, монысы түгел, дип әйтсәм, ул бу иптәшләрне кимсетү булыр иде. Миңа калса, кандидатларның хезмәтләрен тикшермичә генә шундый мәртәбәле премиягә тәкъдим итмиләрдер. Бу яктан каршылыклы фикерләрем юк. Ләкин конкрет шушы әсәре буенча дип әйткәч, кайбер сораулар туа. Башка әсәре лаеграк түгелме икән соң, дип уйлый башлыйсың. Премиянең әдәбият, сәнгатьнең төрле төрләренә бирелүе дә бик уңышлы. Миңа калса, бары тик бер үзенчәлек истә тотылырга тиеш: бу хезмәтләр, һичшиксез, Тукайга бәйле булсыннар иде».

***P.S.*** *Әлеге сорауларга җавап эзләгәндә, башка елларга хас булмаганча, 24 апрель көнне үк Тукай бүләгенә ия булучылар билгеле булды. Ул – «Кол Шәриф мәчете» архитектур комплексын иҗат иткән коллектив. Ни кызганыч: әдәбият белән бәйле кандидатлар барысы да читтә калды.*

## Татар яшьләре



*Габдулла Тукай*

*Дикъкатә лаек хәзерге көн*
*татарның яшьләре:*
*Аңламак, белмәк, тәрәкъкый,*
*мәгърифәт, хикмәт белән*

*Әйләнеп һәм нурланып тормакта*
*һәрдәм башлары.*
*Мондый күрнеш сөйнеченнән*
*инде мин алдан беләм:*

*Тик болар безгә кирәк диңгез төбе*
*гауваслары.*
*Өсттә бу ямьсез болыт*
*баштан китәр, яңгыр явар,*

*Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең*
*изге касдлары.*
*Шаулап аккан су булыр*
*тау башлары, тау астлары.*

*Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү*
*даулашлары,*
*Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре,*
*алмаслары.*

*Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп*
*кашсыз йөзек, -*
*Без аның бик зур фәхерле,*
*чын брилиант кашлары!*

**Дикъкатә лаек -** искә алырга лаек
**Тәрәкъкый -** прогресс
**Һәрдәм -** һәрвакыт
**Гаувас -** чумып энҗе-мәрҗән эзләүче
**Касд -** теләк, омтылыш
**Фәхерле -**мактанычл

## Тукайга тәкълид



*Рифә Рахман*

*«Туйса Иблис тормышыннан*
*Яд итә оҗмахларын»,-*
*ди Тукай. Менә минем дә*
*Сагнып елар чакларым.*

*Тел өчен изге көрәшнең*
*Чишмәдән сафрак чагын,*
*Өметнең буялмый шыткан*
*Ямь-яшел яфрак чагын.*

*Карамый калган җиһанның*
*Кайгысына,аһына,*
*Милләтем,дип җырладык без*
*Аның ирке хакына.*

*Их,күңелнең Мөстәкыйльлек,*
*дигән сүздән хушлыгы!*
*Бу көннең телне тураган*
*Түрәләрнең бушлыгы.*

*Дөньядан бизсәм,сыктыймдыр*
*Көрәшнең данлы чагын.*
*Тугры Түрәдән куркырмы,-*
*Яз, димен, каләм, барын!*

● «Милли хәзинә - 2012»

# Халык җәүһәрләрен барлап

**Башы 1нче биттә.**

Конкурс-фестивальнең сайлап алу турлары бүген, ягъни 26 апрель көнне Филология һәм сәнгать институтында уза. Гала-концерт һәм җиңүчеләрне бүләкләү иртәгә 15 сәгатьтә шушы ук институтның Актлар залында булачак.

Жюри рәисе З.Явгильдина катнашучыларның бик талантлы булуларын әйтеп узды. Аның фикеренчә, аеруча зур игътибарны быел халык кул эшләреннән чигү, агач эшләнмәләр, сувенирлар ясау җәлеп итә. «2013 елгы Универсиадага бәйле сувенирлар ясау хәзерге көндә бик актуаль. Шулай ук безнең милли горефгадәтләрне һәм хәзерге заман таләпләренә туры китереп тегелгән костюмнарны тәкъдим итүче мода театры да бик кызыклы», - диде ул.

Марсель Җаббаров студентлар белән беррәттән, аспирантлар да, укытучылар да катнаша торган «Мизгел» театры турында да бик хисләнеп сөйләде. Әйтеп үтәргә кирәк: бу ел алар өчен бик истәлекле – мизгелләләр 15 еллык юбилейларын бәйрәм итә. Фестивальнең бөтен катнашучылары Г.Камал исемендәге академия театрында куелачак «Беренче мәхәббәт» спектаклен карый алалар, ә инде киләсе елдан «Милли хәзинә» конкурс-фестивалендә театр сәнгате номинациясендә дә катнаша алачаклар.

Барлык «Милли хәзинә» конкурс-фестивале кунакларына да мәдәни-күңел ачу чаралары каралган. Алар Габдулла Тукайга багышланган шигырь бәйрәмендә катнаша алалар, кичә, ягъни 25 апрельдә «УНИКС»та узган «Студентлар язы – 2012» фестиваленең гала-концертын карау мөмкинлеге тудырылган иде, бүген Филология һәм сәнгать институтында алар өчен Россия һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор Рәгъде Халитов иҗатына багышланган концерт уза.



■ «Милли хәзинә»дә катнашучылар Шигърият бәйрәмендә. Рамил Газизов фотосы

● Фән дөньясында

# Тарихчылар - Әлкидә

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә Әлки районы үзәге Базарлы Матакта Россия тарихы һәм Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасы елына багышланган «Туган як буйлап сәяхәт» дип аталган төбәгара фәнни-гамәли конференция узды.

Монда мактаулы кунаклардан КФУ ның Тарих институты профессоры, тарих фәннәре докторы, күренекле тарихчы-археолог, Әлки районының мактаулы гражданины Альберт Борһанов һәм шул ук институтның директор урынбасары Екатерина Кривоножкина катнашты.

Конференциядә катнашучылар бу чараны крайны өйрәнү тарихына багышланган бай фотоматериаллар һәм туган як табигате сурәтләнгән балалар рәсемнәре күргәзмәсен караудан башладылар. Конференцияне районның Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Хәбибуллина ачты. Аннан районның мәгариф идарәсе җитәкчесе А.Хәлиуллинны тыңладылар. Альберт Борһанов исә үз чыгышында Әлки районы тарих укытучылары һәм администрация белән хезмәттәшлек инде бик күптәннән – ТДГИ һәм ТДГПУ эшләгән чорлардан ук килүен, хәзерге көндә федераль университет ректоры И.Гафуров, вуз һәм институтлар җитәкчелеге авыл мәктәпләре белән актив эшчәнлеккә зур игътибар бирүен билгеләп үтте.

Заманында А.Борһанов урта гасырдан ук килгән Иске Нократ, Әлки тарихи һәйкәлләре булган җирләрдә киңкырлы казу эшләре алып барган иде. 2005 елда тапкан хәзинәләр хәзер С.Лисенков исемендәге район музее экспозицияләрен бизи. Галим Әлки районы тарихы һәм мәдәниятенә багышланган тарихчы галимнәр һәм крайны өйрәнүче укытучыларның фәнни хезмәтләрен туплаган җыентыкны әзерләп бетергән.

Е.Кривоножкина Тарих институты коллективы киләчәктә республиканың авыл мәктәпләре өчен һәм шулай ук Әлки районы белән бәйле уку-укыту кулланмалары әзерләргә җыенуы турында сөйләде, аннан КФУ ның Тарих институтына укырга керү кагыйдәләре белән таныштырды.

Конкурска тәкъдим ителгән 60 хезмәтнең 11 е бик яхшы дип табылды (шуларның 5 се – укытучыларныкы, 6 сы – укучылар эше). А.Борһанов һәм Е.Кривоножкина җиңүчеләргә, мәктәпләрдә эшләп килә торган туган як музейларының җитәкчеләренә, активистларына грамоталар, сертификатлар һәм тарих турында китаплар бүләк иттеләр, КФУ институтлары эшчәнлеге турында мәгълүмати материаллар да тараттылар.

Конференциядән соң КФУ кунаклары районның туган як музеенда да булды.

● Табигать сагында







# Чисталык үзебездән башлана

**Гөлшаһидә ДАУТОВА,**
ifi.kpfu.ru сайты хәбәрчесе

Кыш үтүгә, традицион рәвештә республикада шимбә өмәләре старт алды. Шул уңайдан Казан университетының Филология һәм сәнгать институты студентлары шәһәребезнең Зооботаника бакчасын җыештырырга барды.

Казан Зооботаника бакчасы хезмәткәрләре фикеренчә, «кече туганнарыбызга» булган мөнәсәбәтебез культурабызны чагылдыра. Хайван-җәнлекләргә булышып, без үзебездә һәм балаларыбызда мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбиялибез. Алга таба да студентларыбызның ярдәмен тоеп яшәргә теләүләрен җиткерде Зооботаника бакчасы хезмәткәрләре.

Билгеле ки, студентлар – күңелле халык. Өмә барышында да уен-көлке, шаян сүз шактый яңгырады. Биредәге җәнлекләрнең яшәеше белән танышкан студентлар гаҗәпләнү хисләрен яшермәде: кайбер җан ияләрен алар тәүге тапкыр күрде.

Роман-герман филологиясе бүлеге студенты Гүзәл Әбдрәшитова сүзләренчә, мондый чараларның әһәмияте зур. Табигатьне саклау, җәнлек-җанварлар турында кайгырту – һәркемнең бурычы. «Без ихлас йөрәктән Казанның Зооботаника бакчасы хезмәткәрләренә булыштык, аралашып, мәрхәмәтле гамәл кылып, бер көлтә уңай тәэсир алдык», – ди Гүзәл.

Волонтёрларның әлеге ярдәме, әлбәттә, югары бәяләнде, рәхмәт сүзләренә төрелде. Мондый чаралар алга таба тагын да артыр дигән өметтә калабыз.

● Мәсьәләгә бер караш

# Казанда хәлләр «2»лелек!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Сезнең берәр кайчан «Әгәр мин инвалид булсам», – дигән начар уйларга бирелеп, үзегезне шәһәребез урамнарында интегүче житешсез яклары булган кешеләр урынына куеп караганыгыз бармы? Юк шул... Ходай мондый кайгылы күренешләрне дошманыңа да бирмәсен икән... 24 апрель көнне Казан федераль университетында «Киртәләрсез шәһәр» дигән күргәзмә ачылды. Ул 31 майга кадәр эшләячәк.









■ Европа шәһәрләре транспортларында инвалидларга тудырылган шартлар

Алия Галимуллина фотолары

Соңгы елларда инвалидлар өчен нидер эшләнә башлады кебек. Ләкин инвалидлар һаман чаң суга, чөнки күп сүзләр аткан ук кебек әйтелә дә юкка чыга. Сау-сәламәт кеше аларның күңел халәтен, башкалар белән бер дәрәҗәдә буласылары килгәнне аңламый. Бик авыр булса да, берничә мизгелгә генә үзегезне алар урынына куеп карагыз һәм безнең башкалабыз урамнарын, төрле оешма, күңел ачу урыннары, кибет-даруханәләргә кирә торган җирләрне күз алдыгызга китерегез. Алар сезнең өчен гадәти тоелган маршрут буенча уку йортына яисә эш урынына, кибеткә, дуслары белән очрашуга барып җитә аламы? Театр, концерт заллары, музей һәм кафелар алар өчен яраклаштырып эшләнгәнме? Гомумән, белем алып, эшкә урнаша алалармы? Җавап бер генә: ЮК! Алар хәтта юл аша да чыгып җитә алмаячак, чөнки юл кырыйларындагы биек бордюрлар, тротуарда туктап тора торган машиналар, светофорларның тавышсыз булуы яки тиз януы сау-сәламәт кеше өчен дә уңайсызлыклар тудыра.

Күргәзмә материаллары җанны тетрәндерердәй мизгелләр, урыннарны чагылдыра. Алар хәтта, үз проблемаларын чишү өчен, шәһәребезнең Башкарма комитетына, мэриягә, суд биналарына да үтеп керә алмый. Фотолар сүзсез генә шул проблемалар турында сөйли. Ике композициягә бүленгән күргәзмәдә Казан шәһәрендә төшерелгән 39 фотосурәт һәм Европаның Стокгольм, Турку, Гуйттинене, Таллин, Гиисен, Хельсинки һ.б. шәһәрләрендә төшерелгән 33 фотосурәт тәкъдим ителә. Аерма җир белән күк арасы кебек, гәрчә безнең алардан артыграк яши алырдай мөмкинлекләребез булса да.

Ачылу тантанасына килгән Артем Исаев чараны оештыручыларга, әлеге проблемалардан читтә калмаучы һәр кешегә рәхмәт сүзләре җиткерде. «Кайберәүләр проблемаларны читләтеп үтәргә тырыша, ләкин безне онытмаучылар да бар. Заман һаман үзгәрә, Казан төп нормативларны истә тотып үссен иде. Универсиада алдыннан бара торган төзекләндерү вакытында безнең проблемалар да исәпкә алынсын иде. Без кертергә теләгән үзгәрешләр яшь әниләр, велосипед, роликта йөрүчеләр өчен дә файдалы булачак. Ни кызганыч, Казандагы хәлне 5 баллы шкала буенча, күп дигәндә, 2 балл белән генә бәяләргә мөмкин», - диде, үз фикерләре белән уртаклашып. Артем Исаев шулай ук мәдәни-күңел ачу урыннарының да алар өчен уңайсыз булуыннан зарланды. Дан тоткан Камал театры, «Пирамида» күңел ачу үзәге, филармония концертлар залында узган чараларга үтә алмый калган очраклар була икән. Әйтик, Качалов театрының инвалидлар өчен үтү юлы кышка кызыл тасма белән әйләндереп алына, аннан берничек тә кереп булмый.

Александр Калашников актив тормыш рәвеше алып барырга ярата икән. Бу көнне дә күңеле күтәренке иде. «Төнге клубларга йөрисем килә. Ләкин без фейс-контрольны үтә алмыйбыз. Яраткан төркемнәрем килгән очракта гел каршы җавап ишетәм. Безнең дә бит мәдәнияткә, сәнгатькә якын буласыбыз килә», - ди яшь егет. Инвалидар фикеренчә, автобус йөртүчеләрне дә безнең проблемаларны күрергә өйрәтәсе бар. Транспорт чаралары махсус җиһазландырылган булса да, алар я тиешле урында туктамый, я син менеп җиткәнче, ишеген ябып китеп тә бара, я бөтенләй тукталыштан узып китә.

«Европа шәһәрләрендә төшерелгән фотоларга ашкына күңел. Сүз дә юк, бездә нидер эшләнә, ләкин күп вакыт ул үзгәрешләрнең файдасыннан зыяны күбрәк. Берни дә булмаганда, аңларга мөмкин әле, ә нидер үзгәртеп, ул ярдәм итмәсә, бу мыскыл итүгә кайтып кала», - ди алар.

Гасырлар буе төзелгән шәһәрне бер көндә үзгәртеп бетереп булмый. Без инвалидларның гомерләрен сызып ташларга, фикерләрен аяк астына салып ташларга тиеш түгел. Алга таба биналарны үзгәртеп булыр, транспорт чаралары да аларга уңайлы итеп җиһазландырылыр, тавышлы светофорлар да күбрәк эшли башлар, тукталыш исемнәре язылып куелыр. Барысы да вакыт эше... Беренче чиратта, без аларга карата мөнәсәбәтебезне үзгәртергә, проблемаларын күрә белергә, хөрмәт-ихтирам күрсәтергә тиеш. Барыбыз да тигез хокуклы икәнне онытмаска иде дә бит...




DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.